ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.06.2019 Алексеевск ш.т.б. № 264

**«Алексеевск муниципаль районы милкендә булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару Кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 20 маендагы 211 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. «Алексеевск муниципаль районы милкендә булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару Кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 20 маендагы 211 номерлы карарына кушымтаның 4.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Исемлекне раслау яисә аңа үзгәрешләр кертелгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча Кертелә торган исемлек һәм үзгәрешләр массакүләм мәгълүмат чараларында мәҗбүри бастырып чыгарылырга, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга тиеш.»

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе М.Р.Гайсинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**